*Мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм әти-әниләр өчен чыгарыла торган журнал*

# НӘНИ КУКМАРАЛЫ

0+







Кадерле дуслар!

Без сезгә “Нәни кукмаралы” балалар журналын тәкъдим итәбез.

Журналыбыз нәни кызлар һәм малайлар, аларның әти-әниләре өчен.

Сез журнал герое белән Кукмара шәһәре буенча мавыктыргыч сәяхәткә чыгачаксыз. Төрле кызыклы кроссвордлар, мавыктыргыч лабиринтлар, биремнәр башкарачаксыз.

Нәни дусларым, сәяхәткә рәхим итегез!





Сәлам дуслар!!!
Мин сезне шәһәребез
буенча мавыктыргыч
сәяхәткә чакырам. Бүген
Кукмарабызның төрле
милләт халыкларында
кунакта булырбыз.
Я, дускаем, киттекме?











## *Кызыкмы? Кызык!*







**Дуслар, безнең районда бик күп төрле милләт вәкилләре яши - татарлар, руслар, удмуртлар, марилар, керәшеннәр һ.б. Алар төрле телдә сөйләшәләр, һәрберсенең үз гореф-гадәтләре, җырлары, уеннары, әкиятләре. Кукмара халкы бик дус һәм тату яши.**

**Кукмара шәһәренә ике мари нигез салган дип уйлыйлар, ләкин бу җирләргә иң беренчеләрдән татарлар һәм удмуртлар килеп урнашкан.**

**Алар сыер, дуңгыз, сарык, тавык, каз үрчеткәннәр, игенчелек белән дә шөгыльләнгәннәр.**

**Кыр эшләре тәмамлангач, татар халык бәйрәме “Җыен”, керәшеннәрнең “Питрау”, удмуртларның “Гырон быдтон” бәйрәмнәре үткәрелгән.**














**Димитриев Сергей Димитриевич – Кукмара районы башлыгы.**

**1982 нче елның 13 ноябрендә Кукмара районының Пчеловод авылында туа.**

**2005 нче елны Н. Э. Бауман исемендәге Казан дәүләт ветеринария медицина академиясен тәмамлый.**

**Хезмәт эшчәнлеген 2006 нчы елда “Элита” авыл хуҗалыгы оешмасында баш зоотехник булып башлый.**

**2007 нче елны Кукмара районының «Восток» оешмасында башкарма директор вазыйфасын башкара. 2014-2015 нче елларда Татарстан Республикасының Кукмара муниципаль районында башкарма комитет җитәкчесе була.**

**2015 нче елның сентябрь аеннан Кукмара муниципаль районы башлыгы.**

**Сергей Димитриевич җитәкчелегендә Кукмарага шәһәр статусы бирелә. Кукмара киңәя бара, яңа йортлар, юллар, парклар төзелә.**





# Гербны буя





Безнең Кукмара районы күпмилләтле. Шуңа күрә район үзәгендә Халыклар дуслыгы йорты оештырыла. Җитәкчесе Гареева Гөлнара Закирҗан кызы. Аның эше ни дәрәҗәдә кызыклы һәм мөһим икәнлеген белер өчен, без Гөлнара апаны балалар бакчасына кунакка чакырдык.





Мин Халыклар дуслыгы йорты җитәкчесе. Безнең районда татар, удмурт, рус, мари, керәшен халыклары яши. Аларның күпчелеге татарлар – 78 процент, удмуртлар 7,5 мең кеше. Татарстан Республикасы буенча удмуртлар саны 23 мең, өчтән бер өлеше безнең районда яши. Бездә шулай ук мари милләте дә бар, алар 750 кеше, ә рус милләт халкы саны 2 меңгә җитә. Төрле милләт халкының дус-тату яшәве, бер-берсенең гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, телен хөрмәт итүе - минем эшемнең төп максаты. Районыбыз халкы татарча һәм русча җиңел аралаша, ә кайберсе удмурт һәм мари телләрендә сөйләшә. Шулай ук бездә башкорт, чуваш, мордва, вьетнам, украина, әзербайҗан, корея, таджик, төрекмән, үзбәк, якут һәм башка милләтләр яши. Алар барысы үзара дус, тату, бердәм яшиләр.



*Камиль:*
Сез үз эшегезне яратасызмы?



Күп еллар буе мин төрле милләт халыклары белән эш алып барам, аларның мәдәнияте, теле, гореф-гадәтләре миңа бик ошый. Шуңа күрә мин үз эшемне бик яратам.

# *Яшь журналист*



*Ясминә:*
Сезгә нинди милләт ризыклары ошый?

Бигрәк тә, миңа үзебезнең, татар халык милли ризыклары чәк-чәк, коймак, бәлеш, өчпочмак ошый. Удмуртларның перепичи дигән милли ризыгы бар, ул шундый кечкенә, бәрәңге, эремчек салынган пәрәмәч. Шушы милли ризык белән 2005 нче елны Казанда, без кунакларны каршы алдык. Бу ризык аларга бик ошады.



*Арсений:*
Безнең районында нинди милли бәйрәмнәр үткәрелә?



Рәхмәт, бик кызыклы сорау. Районыбызда бер милли бәйрәм дә игьтибарсыз калмый. Тиздән, 2 нче июньдә Республика күләмендә мари халкының милли бәйрәме «Семык» үткәрелү күздә тотыла. Бу бәйрәм язгы кыр эшләре тәмамлангач үткәрелә. Бәйрәмгә республиканың төрле төбәкләреннән кунаклар көтелә. Узган ел районыбызда удмурт милли бәйрәме «Удмуртские напевы» булып узды. Анда Рәсәйнең төрле төбәкләреннән: Пермь, Башкортостан, Петербург, Мәскәү кунаклары чыгыш ясады. Моннан кала районыбызда «Сабантуй», «Гырон Быдтон», «Крещение», «Рождество», «Масленица», «Яблочный спас», «Медовый спас» бәйрәмнәре зурлап үткәрелә.



*Аяз:*
Сез хайваннар яратасызмы?

Мин йорт хайваннарын бик яратам. Балачакта безнең ике сыерыбыз бар иде, 3 нче сыйныфта укыганда мин инде сыер сава белә идем. Хәзерге вакытта безнең ау этебез бар. Ул төрле командаларга өйрәтелгән.

# Яшь журналист



*Раяз:*
Сезнең яраткан шөгылегез?

Мин эшләргә яратам. Нинди генә эшкә тотынсам да, мин аңа зур кызыксыну белән алынам. Моннан кала, районда туризм үсеше һәм иске тарихи биналарны торгызу эше белән шөгыльләнәм. Хәзерге вакытта сезнең балалар бакчасы каршындагы итек комбинатына нигез салучы В.Н.Комаров йортын төзекләндерү өстендә эш алып барыла.

*Альбина:*
Сезнең балачак хыялыгыз?





Балачакта укытучы булу теләге көчле иде. Мәктәпне тәмамлагач Казан дәүләт университетының физика-математика бүлегенә укырга кердем, мин - математика укытучысы. Шулай итеп, мин балачак хыялымны тормышка ашырдым.

*Ландыш:*
Ускәч нинди хыялыгыз тормышка ашты?



Минем үскәч, гаилә корып, кыз балалар тәрбиялисем килде. Бу теләгем дә тормышка ашты. Ике кыз бала үстерәм, алар инде зурлар. Мәктәпне алтын медальга тәмамлап, финанс-экономика институтын кызыл дипломга бетерделәр. Мин алар белән горурланам.

*Ландыш:*
Җавапларыгыз өчен рәхмәт!



# Лабиринт





# Милләтләр



**Кукмара районы халкы:**
**татарлар – 78,6%;**
**удмуртлар – 14,0%;**
**руслар – 5,3%;**
**марилар – 1,4%**





Татарлар (үзатамасы — тат. татарлар, tatarlar) — төрки этноска керүче, Рәсәйнең европа өлешендә, Идел-Уралда яшәүчеләр. Этник төркеме: казан татарлары, мишәрләр, керәшеннәр, себер, әстерхан татарлары.

Руслар ( XX гасыр башына кадәр «великороссы» этнонимы өстенлек иткән) —көньяк славян этносы, Рәсәйнең күпчелек халкы.



# *Милләтләр*



**Кукмара районы халкы:**
**татарлар – 78,6%;**
**удмуртлар – 14,0%;**
**руслар – 5,3%;**
**марилар – 1,4%**



Удмуртлар (удмурт, удморт, күп.с.. удмуртъёс; искергән рус атамасы— вотяки) — фин-угор халкы,нигездә Удмуртия Республикасында һәм күрше төбәкләрдә яшәүче халык.




Марилар (мари, марий, мары, маре, мере, мäрӹ; искергән рус атамасы — черемисы) — фин-угор халкы, нигездә Марий Эл Республикасында һәм Рәсәй җирлегендә яшәүче халык.



# 8 аерманы тап!




# Шәүләсен тап



# Кукмара металл савыт-саба заводы «Kuktara»

*Бар һөнәр дә кирәк,*
*Бар һөнәр дә мөһим.*









**ААЖ «Кукмара металл савыт-саба заводы» – бүгенге көндә Россиянең төп алюмин савыт-саба җитештерүчеләрнең берсе булып тора. 1950 нче елда нигез салына. Савыт-саба югары сыйфаты,уңайлылыгы, затлылыгы белән аерылып тора.**





**Алюминийдан ясалган савыт-саба ассортименты елдан-ел төрлеләнә. Завод казаннар, төрле табалар, кәстрүлләр, печенье табалары, ипи формалары чыгара.**





# *Кубик һәм фишкалар белән өстәл уены*



# Кызыклы урыннар

***«Хыял» тегү фабрикасы***



***Бар һөнәр дә кирәк,
Бар һөнәр дә файдалы.***





**ААЖ «Кукмара тегү фабрикасы»на 1956 нчы елда нигез салына. Бүгенге көндә дә Татарстан Республикасы буенча алдынгылар рәтендә. Фабриканың җитештерелгән киемнәре Кукмараның данын бик еракларга тарата.**

**Дизайнерлар үзләренең бай тәҗрибәләрен кулланып заманча моделльләр иҗат итәләр.**






***Кукмара киез-итек комбинаты***



КУКМОРСКИЕ ВАЛЕНКИ

**ААЖ «Кукмара киез-итек комбинаты»на 1867 нче елда нигез салына. Фабрикада киездән төрле аяк киемнәре – угги, чулки, тапочкалар, чүни, ботинкалар, сапогилар һәм кроссовкалар эшләнелә. Бу аяк киемнәре шәһәр җире өчен дә бик кулай. Соңгы елларда комбинат заманча технологияләр кулланып, чигү, мех, күн һәм бисер белән бизәлгән модельләр җитештерә.**



# Курчакны киендер



# Башваткыч































# Уйнап, телләр өйрәнәбез





















**Дуслар, миңа татар, рус, удмурт һәм мари халыкларының милли ризыкларын табарга ярдәм итегез әле!**

# Татар халык милли костюмын буя

**1 pink**
**ал**

**2 red**
**кызыл**

**3 yellow**
**сары**

**4 brown**
**көрән**

**5 black**
**кара**

**6 blue**
**зәңгәр**






3 5 1 6 2 4

М Р У Т Д У

1 2 3

Р У С

3 4 2 5 1 6 7

Р Ә Е Ш К Е Н

3 1 2 4

Р М А И

5 2 1 4 3

Р А Т А Т



**Татар халык табышмагы**

*Мин торам кырларда,*
*болында, урманда*
*Уйныймын, очамын якты*
*көн булганда.*
*(Күбәләк)*





**Рус халык табышмагы**

*Кара түтәлдә,*
*Үсә бер сылу,*
*Кулга алалар, чәчен өзәләр.*
*(Кишер)*

**Удмурт халык табышмагы**

*Башы - пычкыдай,*
*койрыгы-урактай.*
*(Әтәч)*





**Мари халык табышмагы**

*Басу тирәли ак япма төшкән.*
*(Томан)*

# Уйлап кара

***Дуслар, миңа милләтләрнең парын табарга ярдәм итегез әле!***



















# Кисмә рәсемнәр










# Музыкаль ноталар

***Музыкаль инструментларны таны. Алар кайсы милләт халкына туры килә?***



**Думбра**



**Кашыклар**



**Гармун**



**Балалайка**



**Кубыз**



**Шакылдавык**



**Курай-сыбызгы**



# Рәсем күргәзмәсе «Кукмарам»

## “Гөрләвек” балалар бакчасы




Әхмәтҗанов Аяз



Андреева Алина



Галәветдинова Азалия



Бәдретдинова Алия



Әхтәмова Раяна



Захаров Тимур



Кашипов Айназ



Низамеев Ильдан



Сәләхова Илзия




Шәмсетдинов Әльфир



Андриев Максим




Әхмәтова Әдилә




Токтаров Даниель




Фалахова Алсу



Хафизов Данияр



Гарифуллина Сирина



Шарипов Раяз



Галиева Айсина



Гилязова Алина



Халиуллин Әмир




Токтаров Даниель



Фазлеев Булат

# Рәсемнәр күргәзмәсе «Күпмилләтле Кукмара»



Хакимуллина Дарина



Гыйззатуллин Рузаль



Гайнанова Диана



Гилемуллин Идрис



Хисматова Айлүзә



Фазлеев Булат



Фазлеев Булат



Харрасова Хәнифә



Мохтаров
Исмаил һәм Идрис



Хабирова Сәминә



Ишмуратов Давыт



Сәләхова Илзия


# Җаваплар



18нче бит




12нче бит







23нче бит



22нче бит

**Кашыклар – урыс халык инструменты**
**Гармун - татар халык инструменты**
**Думбра - татар халык инструменты**
**Балалайка – урыс халык инструменты**
**Курай-сыбызгы – мари халык инструменты**
**Кубыз – удмурт халык инструменты**

24нче бит



9нчы бит

**УДМУРТ**
**УРЫС**
**КЕРӘШЕН**
**МАРИ**
**Т А Т АР**

20нче бит

**Башваткыч:**
**1. горнолыжка;**
**2. Олимп;**
**3. Нурминка; 4. Хыял;**
**5.вокзал; 6. Зилант;**
**7. музей; 8. парк.**

17нче бит

# Киләсе очрашуларга кадәр, кадерле дуслар!



**Журналның автор-төзүчеләре:**
**Кукмара шәһәренең 8 нче номерлы «Гөрләвек» балалар бакчасы хезмәткәрләре, тәрбияләнүче балалар һәм әти-әниләр**
**422110, Кукмара шәһәре, Ворошилов урамы, 19 нчы йорт**
**тел. 8(84364)2-61-50**
**Балалар бакчасының онлайн журналыннан, рәсми сайтыннан бастырылды.**
**Сайт адресы https://edu.tatar.ru/kukmor/dou6_raduga/dou8_rucheek**